ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.02.2020 п.г.т.Алексеевское № 66

**«Гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә тикшерүләр уздыруның административ регламентын раслау турында» Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 18 октябрендәге 475 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан районара табигатьне саклау прокуратурасының 2020 елның 18 февралендәге 02-06-2020/3 протесты нигезендә

**карар кылам:**

1. Административ регламент пунктларын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалануны һәм аларны саклауны тикшереп тору керә.»

«3.5. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан расланган план буенча тикшерүләр үткәрү планы кызыксынган затларга аны «Интернет» челтәрендәге муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән яисә башка мөмкин булган ысул белән җиткерелә.»

«8.1. Җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир биләүчеләр һәм җир кишәрлекләрен арендага алучылар йә аларның законлы

вәкилләре муниципаль җир контроле буенча чаралар уздырганда түбәндәгеләргә хокуклы:

1) тикшерү үткәргәндә турыдан-туры катнашырга, тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

2) муниципаль контроль органыннан, аларның вазыйфаи затларыннан тикшерү предметына караган һәм бирү Федераль законда каралган мәгълүматны алырга;

2.1) башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан йә шушы документлар һәм (яисә) мәгълүмат булган дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына караган оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында муниципаль контроль органнары тарафыннан алынган документлар һәм (яисә) мәгълүмат белән танышырга;

2.2) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алына торган документларны һәм (яисә) мәгълүматны дәүләт контроле (күзәтчелеге) органына, үз инициативасы белән муниципаль контроль органына тапшырырга;

3) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында тикшерү нәтиҗәләре белән, алар белән, шулай ук дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының аерым гамәлләре белән танышуы турында күрсәтергә;

4) тикшерү уздырганда юридик затның, индивидуаль эшкуарның хокукларын бозуга китергән дәүләт контроле (күзәтчелек) органы, муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яисә) суд тәртибендә шикаять бирергә;

5) Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне йә Россия Федерациясе субъектында эшкуарларның хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне тикшерүдә катнашуга җәлеп итәргә.»

2. «Планлы тикшерүләрне оештыру һәм уздыру тәртибе» Административ регламентының 3 бүлеген 3.10 пункты белән тулыландырырга:

«3.10. Планлы яисә планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү индивидуаль эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле, җитәкче яисә юридик затның башка вазыйфаи заты булмауга бәйле йә юридик зат, индивидуаль эшкуар эшчәнлегенең факттагы кабатланмавына, яисә аның вәкаләтле вәкиле, юридик затның вәкаләтле вәкиле, җитәкче яисә башка вазыйфаи заты, тикшерү үткәрү мөмкинлеге булмауга китергән юридик затның башка гамәлләре (гамәл кылмавы) белән бәйле булган очракта, муниципаль контроль органының вазыйфаи заты, аны үткәрү мөмкин булмау сәбәпләрен күрсәтеп, тиешле тикшерүне үткәрү мөмкинлеге булмау турында акт төзи. Бу очракта муниципаль контроль органы тиешле тикшерүне үткәрү мөмкинлеге булмау турында акт төзегән көннән алып өч ай эчендә мондый юридик затка, шәхси эшкуарга планлы тикшерүне планлаштырылган тикшерүләрнең еллык планына кертмичә һәм юридик затка, шәхси эшкуарга алдан хәбәр итмичә генә үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы.»

3. 5.2 пунктта Боерык сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе мөһере белән

таныкланган» сүзләрен өстәргә.

4. 6.3, 6.4 пунктларын түбәндәге абзац белән тулыландырырга:

Тикшерелә торган затның муниципаль контроль кысаларында электрон рәвештә багланышлар алып баруга ризалыгы булганда, тикшерү акты төзелгән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында әлеге акт төзегән затка, җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленә, индивидуаль эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган, тикшерелә торган затка әлеге документны алуны раслауны тәэмин итүче ысул белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелгән акт тикшерелүче зат тарафыннан алынган дип санала.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе М.Р. Гайсинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**